**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы**

К А Р А Р

**№ 15 Кәрәкәшле ав. «15» июнь 2015 ел**

Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауны билгеләү турында

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында"гы Федераль законның 10 маддәсендәге 3, 7 пунктларына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 маддәсендәге 2 өлешенә, 105 маддәсендәге 1 өлешенә, «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 маддәсенә ярашлы рәвештә, Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны 2015 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Ютазы таңы» газетасында кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http:// jutaza.tatar.ru.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Дәүләтгәрәев